**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Мәсгут авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Мәсгут авылы № 32 “ 03 ” октябрь 2016 ел

Мәсгут авылы җирлеге биләмәсендә
узарасалым җыю һәм куллану
буенча, җирле референдум үткәрү
көнен билгеләү турында.

2002 елелның 12 июнендә кабул ителгән “Россия Федерациясе гражданнарының референдумда катнашу һәм сайлау хокукларының төп гарантияләре” турындагы 67 номерлы Федераль законның 15 статьясы, 2003 елның 06 октябрендә кабул ителгән “Россия Федерациясендә җирле узидарәне оештыруның уртак принциплары” турындагы 113 номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, 2004 елның 24 мартында кабул ителгән “Җирле референдум” турындагы 23 номерлы Татарстан Республикасы законы, Мәсгут авыл җирлеге Уставының 12 статьясы Мәсгут авылы башкарма комитетының 29 январь 2016 елда чыккан 01 номерлы “Җирле референдум үткәрү” карары, Мәсгут авыл җирлеге Советының 29 январь 2016 елда чыккан “Җирле референдум үткәрү” карары нигезләрендә,

Мәсгут авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Мәсгут авыл җирлеге биләмәсендә узарасалым җыю һәм куллану буенча 20 ноябрь 2016 ел көнне референдум үткәрергә.
2. Референдумда караласы мәсьәлә:

“Сез, Мәсгут авыл җирлеге биләмәсендә теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 2016 елда 350 сум күләмендә узарасалым җыю белән килешәсезме. Узарасалым түләүдән көндезге якта укучы студентлар, 1 группа инвалидлар азат ителә. Узарасалымнан кергән керем түбәндәге юнәлештә тотыла:

1) Авыл эчендәге юлларны ремонтлау-40 000 сум , шуның эченнән:
- *вак ташлар белән юлларны күтәртү һәм тигезләү эшләре Мәсгут авылында - 40 000 сум;*

2) Яшәү торакларының беренчел янгын куркынычсызлыгын тәэмин итеп, гражданнарның 20 000 сум күләмендәге узарасалымын сарыф итү;

- *кисэту жайланмалары урнаштыру – 20 000 сум;*

3) Балалар мәйданчыгы тозу, гражданнарнын 38 000 сум күләмендәге узарасалымын сарыф итү;

- *Балалар мәйданчыгы тозу – 38 000 сум;*

ӘЙЕ ЮК

3. Карар районның “Маяк” газетасында бастырыла һәм Азнакай муниципаль районының Интернет челтәрендә http://aznakyevo.tatarstan.ru веб – адресы буенча урнаштырыла.
4. Карар газетада бастырылып чыккан көненнән көченә керә.

Председатель: Э. А. Габдрахманов